**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 июль № 502

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

2.1 нче пунктта «конкурсны үткәрү елы алдыннан килгән ел дәвамында» сүзләрен «конкурсны үткәрү елы алдыннан килгән елның 1 сентябреннән башлап конкурсны үткәрү елының 31 августына кадәрге чорда» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Конкурс комиссиясенең йомгаклау утырышы 20 ноябрьдән дә соңга калмыйча үткәрелә.»;

4.2 нче пунктта «конкурс үткәрелү көненә кадәр 30 календарь көн алдан» сүзләрен «1 сентябрьдән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 нче пунктта «тапшырыла» сүзенә кадәр «1 октябрьдән 30 октябрьгә кадәрге чорда» сүзләрен өстәргә.

IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.16 нчы пункт өстәргә:

«4.16. Премияләрне бирү ел саен Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне – 9 декабрьдә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү буенча комиссия составында:

комиссия составыннан А.А.Ощепковны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Марат Бәһрам улы Сөнгатуллинны | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручыны; |
| Наталья Владимировна Фоминаны | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\502.docx